**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 95

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2011 ел, 10 февраль, 83 нче; 2013 ел, 1 март, 141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәнең 2 нче пунктындагы «100,0» санын «200,0» санына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан Р.Т.Борһановны, А.С.Кондратьевны, Т.Н.Вафинаны, В.Х.Хәбибуллинаны, Д.М.Мостафинны, Р.Г.Галиуллинны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры, Комитет рәисе Владимир Александрович Леоновны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы, Комитет рәисе урынбасары Гүзәл Рәис кызы Шакированы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы Гөлшат Рәдиф кызы Нигъмәтуллинаны;

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Светлана Владимировна Гыйниатуллинаны;

«Идел» журналы баш мөхәррире Радик Рәшид улы Сабировны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының балалар һәм яшьләр оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы Владислав Викторович Усановны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\95.doc